**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2016 елның 20 декабре №63

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) рәсми чыганаклары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карары:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын һәм башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару чыганагы итеп түбәндәге массакүләм мәгълүмат чараларын билгеләргә:
- «Зеленодольская правда» газетасы яки «Яшел Үзән» газетасы.
- Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Карамалы Тау ш.т.б., Беренче Май ур., 70 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының административ бинасы.

2. Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару өчен кирәкле чаралар күрергә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы һәм әлеге карар таләпләре нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганаклары турында «2012 елның 18 октябрендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карары» үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Җирлек Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Ф.Н. Шәмсиев**